ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Старые Уруссу, ул.Советская,
д.16в, , 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 4 16.11. 2020 ел.

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Иске Урыссу торак пунктында 2021 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Урыссу авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге башлыгы
К А Р А Р  И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Иске Урыссу авылы, Совет ур., 45Б нчы йорт адресы буенча урнашкан "Иске Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе бинасы янында 2020 елның 27 ноябренә 14.00 сәгатьтә Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Иске Урыссу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш 2021 елда үзара салым кертүгә 1500 сум күләмендә түләргә  һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга ризамы:

- Октябрь урамы, Елга урамы, 1 Май урамы буенча Иске Урыссу торак пункты юлларын норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, асфальт салу, ремонт, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Урыссу бистәсендә Хәтер скверын төзү (проект төзү, проект төзү буенча хезмәтләр, төзелеш материаллары һәм җиһазлары сатып алу, сквер территориясенә нигез салу, мемориал сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Иске Урыссу торак пункты юлларын кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatarstan.ru веб-адрес буенча - Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова